
# Ял сәгатьләрендә

## Кроссворд



**Сулдан уңга:** **1. Балигъ булмаган малай яки кыз. 5. Дүртпочмаклап эшләнгән бүрәнә корылма. 8. Тирбәлә торган яшь бала ятагы. 9. Кимерүче урман җәнлеге. 11. Музыка уен коралы. 12. Арча районындагы “пәриле” авыл. 13. Авызында агулы бизләре булган сөйрәлүче хайван. 16. Атаклы татар химигы. 17. XIX гасырда яшәгән татар шагыйре. 19. Чикерткә сыман үлән ашаучы бөҗәк. 21. Акча (искечә). 25. Җиләк бирә торган икееллык куак. 26. Кариб диңгезендәге дәүләт, башкаласы - Гавана. 29.Озынча кун тасма. 30. Сугышта дошман кулына төшкән тоткын. 31. Бергә яшәүче ир, хатын, балалар төркеме. 32. Һ. Такташ поэмасы. 33. Зур бәла-каза.**

**Өстән аска:** **1. Күз тиюдән саклаучы догалар . 2.ТР үзәк өлешенә урнашкан район. 3. Билгеле бер мәсьәлә буенча фикер алышу. 4. Татарстанда нәшер ителүче газета. 6. Планета. 7. Җиде көн. 10. Фин култыгына коючы елга. 11. Азәрбайҗан башкаласы. 14. Рухлар белән бәйләнештә торучы, им-томчы. 15. Киемдә төймәләү өчен уеп, кисеп ясалган тишек. 18. Тиеннең бер төре. 20. Г. Тукайның бала чагындагы кушаматы. 22. Бик затлы һәм татлы ризык, сөтле ботка. 23. Ерткыч диңгез балыгы. 24. Алмагачның хш исле, татлы җимеше. 25. Кремний (IV) оксиды, кыйммәтле асылташ. 27. М. Мәһдиевнең “Ут чәчәге” әсәре герое. 28. Урта диңгезнең көнчыгыш өлешендәге ...ау.**



## Табышмаклы криптограмма

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Һ | Ө | с | т | ә | р | ь | У | Ш |
| Һ | у | л | ә | к | а | т | р | ә |
| ә | Д | д | Ш | и | г | н | ы | м |
| ж | ө | я | и | С | ә | л | г | е |
| ә | М | и | ч | л | к | ы | з | Һ |
| М | Т | н | е | н | ь | К | ө | а |
| ә | К | е | К | Т | К | и | Э | ш |
| ч | п | р | у | е | р | ү | в | т |
| е | е | н | я | ш | л | ә | з | к |

1. **Җансыз җанлыны уята.**
2. **Дүрт малайга бер түбәтәй.**
3. **Читтән карасам – аклы, татып карасам - татлы.**
4. **Башы бер, күзе унике.**
5. **Түтәрәм, түтәрәм, кунакны мин күтәрәм.**
6. **Кечкенә генә мелде, миңа карап көлде.**
7. **Багана яна, күмере-көле юк.**
8. **Бер бүкәндә җиде тишек.**
9. **Кешенең дусты, йортның сакчысы.**
10. **Сакаллы кыз.**
11. **Коры җирнен көймәсе.**
12. **Караңгыда карт әби балык тотып утыра.**
13. **Ак күлмәк кигән, башы түшәмгә тигән.**
14. **Кош түгел, оча, ябалактан курка, чикләвек ярата.**
15. **Яланда энәле йомгакятыр.**
16. **Җәен соры, кышын ак, аңа шулай яхшырак.**
17. **Ике күрше бер-берсен күрә алмый.**
18. **Үзе утыз, урыны кызыл, һичкем аннан буш булмас.**

**Газетаны оештыручылар һәм редколлегия әгъзалары:** Зиятова Дилбәр Хәлил кызы, Фатыхова Сәрия Дамировна, Әхмәтгалиева Эльмира Алис кызы, Мифтахетдинова Фирдания Ансар кызы

**Индекс-** 422020

**Адрес:** ТР, Арча муниципаль районы ,Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 2 йорт.

Март ,2025
№ 3



МБОУ «Ново-Кырлайская СОШ имени Г.Тукай»
МБГБУ «Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбе»

# ЧИШМӘ БАШЫ

## Хуш киләсең, Рамазан!

1мартта мөселманнар өчен иң хәерле ай башлана. Рамазан ае – барлык ихлас мөэмин-мөселманнар көтеп алган изге ай.

Рамазан – ул бөек мәктәп! Бу үз тормышыңның мәгънәсен аңлау, үз-үзеңне тотышыңны үзгәртү, әхлакый үсеш, камилләшү өчен мөмкинлекләр ае.



# Укучыларыбызның уңышлары

Мәктәбебездә татар әдәбияты фәнен яратып үзләштерүче укучыларыбыз күп. Шундый укучыларыбыз - 8 класстан Хәйдәрова Илүзә һәм 9 класстан Ганеева Алинә. Алар, татар әдәбияты фәненнән Республика олимпиадасында катнашып, үзләренең белемнәренең ныклы икәнлеген тагын бер кат расладылар. Ганеева Алинә призер булды. Кызларыбызга киләчәктә дә зур уңышлар телибез.

***

“Сәйяр” Республика балалар һәм яшүсмерләр театр фестиваленең муниципаль этабында мәктәбебезнең «Күңелле сәхнә” театр коллективы 1 нче урын алды. Коллектив грамота һәм 20 мең сум акча белән бүләкләнде.

***

Бүген 7 март көнне Шушмабаш авылы мәдәният йортында Бариев Габделхай Габделхак улы истәлегенә, "Северный" хуҗалыгы призына 2009-2011 нче елгы һәм аннан яшьрәк егетләр арасында көрәш ярышлары узды. Мәктәбебез укучылары бу ярышта катнашыпүз үлчәүләрендә Минуллин Раяз -1 урынга (38 кг) Зиятов Фәнзиль - 2 урынга (60 кг), Минзин Ильмир - 3 урынга (43 кг) лаек булып кайттылар.

***

"Арча йолдызлары - 2025" конкурс-фестивалендә катнашып Исмагилова Адилә III дәрәҗә лауреат булды. Аңа диплом һәм истәлекле бүләк тапшырылды.












# Юл кагыйдәләрен беләсезме?

Мәктәбебездә кунакта Арча районы профилактика бүлеге җитәкчесе ЮХИДИ хезмәткәре Мухаметзянова Энже Газиз кызы булды. 6 сыйныф укучылары, сыйныф җитәкчесе Рәхимова Р.И.кызы җитәкчелегендә әти-әниләр белән "Юл кагыйдәләрен беләсезме?" исемле КВН уены үтте. Чараның төп максаты - юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәүче гражданнар тәрбияләү, балаларның юлда имгәнүен кисәтү. Чара барышында укучылар, ата-аналар үзләренең юлда йөрү буенча белемнәрен күрсәттеләр, яңалыклар белән таныштылар, юл инспекторының сорауларына дөрес итеп җавап бирделәр. Кичә җыр һәм уеннар белән үрелеп барды. Укучыларыбыз да, әниләребез дә кызыклы конкурслар һәм уеннарда бик теләп катнаштылар. Кунагыбыз Энже Газиз кызы чарага югары бәя бирде һәм укучыларга бүләкләр өләште.





# "Халык зур ул, моңлы ул..."төбәкара ачык конкурс-фестифале

Балтач районы Түбән Кенә мәктәбендә узган "Халык зур ул, моңлы ул" төбәкара ачык конкурс-естивалендә 4 класс укучылары, укытучыларыбыз Фатихова С. Д., Мифтахетдинова Ф. А., акироа Г. Ш. 1 нче дәрәҗә, 9 класс укучысы Галимҗанов Ильназ, җитәкчесе Гайфуллина Л. Х. дәрәҗә дипломга лаек булдылар. Котлыйбыз!







***Онытылган гореф-гадәтләрне***
***Яңартабыз хәзер көннән-көн.***
***Уен йолалары, җыр-биюе***
***Һәр киләчәк көнне бизәсен***
.

**Халык җырлары-безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәхале бер мирастыр.Әйе бу кадерле мирас,кыйммәтле мирас!**

**Халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска,иҗтиһат итәргә кирәк".**

**Г.Тукай**



# Башлангыч сыйныфларда кинодәресләр проекты

Яңа елдан «Россия мәктәпләрендә кинодәресләр» проекты старт алды, ул укучыларның иҗади дөньяга карашын формалаштыруга һәм җәмгыять файдасына социаль әһәмияткә ия эшчәнлеккә этәрүгә юнәлдерелгән.

Проект Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан хупланды һәм ия эше кысаларында кулланырга тәкъдим ителде.

«Россия мәктәпләрендә Кинодәресләр» проекты кысаларында 1-4 сыйныф җитәкчеләре һәм тәрбия буенча директор киңәшчесе укучылар өчен фильмнар карау оештырды:

"«Мой друг - единорог»" ("Единорог-минем дустым") Е.В. Дубровскаяның шул ук исемдәге хикәясе буенча. Фильм игелек, ярдәмчеллек һәм гаделлек проблемаларына кагылды.

- «Восьмое марта»" (" 8 март ") фильмын укучылар зур кызыксыну белән карадылар. Карап чыкканнан соң, балалар игелекле эшләрне риясыз эшләргә дигән бердәм фикергә килделәр.

"Экзамен" " ("Имтихан") - карау алдыннан укучылар фильмның исем еннән чыгып фикер алыштылар. Фильмны караганнан соң фикер алышу булды, аның барышында балалар үз тәэсирләре белән уртаклаштылар, геройларның гамәлләре һәм фильмда күрсәтелгән хәлнең чынбарлыкка туры килүе турында фикер алыштылар. Балалар теләсә нинди хезмәт кеше өчен бертигез мөһим, шул ук вакытта начар һөнәрләр дә юк дигән нәтиҗә ясады.







# 8 март -иң күркәм бәйрәмнәрнең берсе

Көннең яктылыгы – кояшта,күкнең матурлыгы – йолдызларда, җирнең гүзәллеге – кызларда. 8 март хатын – кызларны олылау көне, матурлык бәйрәме. Әлеге бәйрәм башка бәйрәмнәрдән яктырак та, җылырак та, мөлаемрак та шикелле. Шуңа күрә дә менә бу бәйрәмне кешелек дөньясы 1913 нче елдан ук бәйрәм итеп килә. Сезне бөтен җир йөзен бизәгән яз бәйрәме – Халыкара хатын – кызлар көне белән тәбриклибез. Сезгә озын гомер,елмаеп балкыган кояш матурлыгы,тынгысыз хезмәтегездә, укуыгызда зурдан – зур уңышлар телибез.





# «ҮРНӘК АЛЫЙК»

Мәктәбебездә татар әдәбияты фәнен яратып үзләштерүче укучыларыбыз күп. Шундый укучыларыбыз - 8 класстан Хәйдәрова Илүзә һәм 9 класстан Ганеева Алинә. Алар, татар әдәбияты фәненнән Республика олимпиадасында катнашып, үзләренең белемнәренең ныклы икәнлеген тагын бер кат растадылар. Ганеева Алинә призер булды. Кызларыбызга киләчәктә дә зур уңышлар телибез, һәрвакыт шулай тырыш һәм мәктәбебезнең горурлыгы булып калсыннар. Укытучылары: Зарипова Миләүшә Рафис кызы.









# Иҗат чишмәсе

Язлар җыры

Язлар кайта кошлар канатында
Туган якка ашыгып,ашкынып.
Ял итәләр гүя ак болытка утырып
Бар җиһанны моңга тутырып.

Язлар килә килә кошлар җыры белән
Гөрләвекләр белән ашыгып
Яз тантана итә кар суында
Кояш нуры белән ярышып.

Фатихова С.Д.

Сыерчыгым

Сыерчыклар килгәннәр
Яз килгәнен белгәннәр
Туган якка кайтырга дип
Илләр гизеп килгәннәр.

Чут-чут итеп сайрашып,
Яңа оя сайлыйлар
Көне буе җим ташып
Кичкә бик нык арыйлар

Файзрахманова Илюза 4 класс
,





Ничә генә яшьтә булсак та без,
Һәрчак әни кирәк безнең күңелгә
Күпме таш ыелган күңелләрне –
Әни белә ничек эретергә!
Кая барсак,кайда торсак та без,
Күңел һаман нидер эзләнә,
Чөнки әни булган җирдә генә,
Кәеф яхшы якка үзгәрә.

Әни! Күпме рәхмәт сүзе әйтсәк тә без,
Аз булыр ул,тулмас кук савыт,
Бер аллаһым бирсен иде безгә,
Сезне хөрмәтләргә мул вакыт.
Әни!Рәхмәт сиңа !
Гомер бирдең,назлап үстердең,
Без дип яндың һәрчак,
Без дип йөгердең!
Сау –сәламәт булып яшә ,әнием!
Гел шат булсын синең күңелең!
Без бит сине бик нык яратабыз!
Озын булсын синең гомерең!

Хәйдәров Нур